Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ

№ 15 (28)

17 май 2012 ел

## • Ике авыз сүз

14 май көнне ректоратның чираттагы утырышы узды. Ректоратны административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе Андрей Хашов алып барды.

Беренче булып икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор М.Сафиуллин КФУ ның Үсеш программасына бәйле яңа мәгълүматлар җиткерде.

Алга таба Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 27 апрелендә чыккан боерыгы нигезендә Казан федераль университетына Кама дәүләт инженерия-икътисад академиясен кушу турында сөйләнде. Әлеге мәсьәләгә бәйле барлык сораулар да сайтта урын алачак.

Төрлеләр өлешендә беренче булып КФУ ның хезмәтне саклау бүлеге җитәкчесе Татьяна Зимина укыту процессы һәм хезмәт шартлары куркынычсызлыгын комплекслы рәвештә тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырды. Аның чыгышы презентация рәвешендә эшләнгән фотосурәтләр белән дәлилләнеп барды. Тикшерү 26 марттан башлап 30 апрельгә кадәр Физика институтында, Фундаменталь медицина һәм биология институтында, Технологик үзәктә, Химия институтында уздырыла. Тикшерү барышында, электр, газ һәм янгын куркынычсызлыгы, укыту җиһазларын, химик реактив, биологик матдәләрне саклау, гигиена таләпләрен дөрес үтәмәү һ.б. кагыйдәләрне бозу очраклары табыла. Шулай ук эш урынының кечкенә булуы яисә шунда тәмәке тарту, компьютер чыбыкларының идәндә аунап ятуы яки аларның бер розеткага күпләп тыгылуы куркынычсызлык кагыйдәләренең бөтенләй үтәлмәвен күрсәтә. «Уку йорты комиссиясе тикшергәннән соң, күп кенә җитешсезлекләр төзәтелде, ләкин әле бу юнәлештә башкарасы эшләребез бар. Үз сәламәтлегебезгә игътибарлырак булсак иде», – диде Татьяна Зимина.

Алга таба КФУ ның Яр Чаллы филиалы директоры Анатолий Макаров филология кафедрасын филология һәм коммуникация теориясе кафедрасына үзгәртү, җинаятьләр процессын өйрәнү кафедрасын ачу тәкъдиме белән чыкты. Ректоратта катнашучылар әлеге тәкъдимнәрне бер тавыштан кабул итте.

КФУ Веб-порталының бүлекләр сайтылары турында җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлеге хезмәткәре Эльвира Муллагалиева сөйләде. Әле һаман кайбер институт һәм факультетларның сайтларында мәгълүмат җитеп бетми икән. Аеруча абитуриентлар өчен эшләнәсе эшләр күп. «Техник яктан хәтта һәр кафедра өчен сайт ачарлык мөмкинлекләр бар, бары тик эшне башкара алырдай кешене билгеләп куярга гына кирәк», – диде һәм кайсы институтларга эшне аеруча тизләтергә кирәклеген исемлек ярдәмендә тәкъдим итте.

• • • •

12 май көнне Казан университетында рәсми рәвештә Pricewaterhouse Coopers (PwC) компаниясе стипендиясен алучы финалистларны игълан иттеләр. PwC – дөнья күләмендә консалтинг һәм аудит өлкәсе буенча профессиональ хезмәт күрсәтә торган иң эре халыкара компанияләр челтәре. Алдагы уку елында Яна Вафина, Кирилл Финогеев, Нәфис Мөхәммәтгалиев, Дарья Буторина, Руфинә Гатауллина ай саен 3 мең күләмендә стипендия алачак. Катнашучыларга сайлап алу турларында җиңүгә ирешү җиңел бирелми, чөнки бер урынга 9 кеше дәгъва кылган.

• • • •

14 май көнне Алабуга шәһәренең мәдәният сараенда, «Ирекле территория» төбәкара җәмәгать оешмасы, шәһәр волонтёрлары һәм Яр Чаллы, Алабуга КВН командалары тарафыннан әзерләнеп, иганәчелек эшенә юнәлтелгән «Игелекле эшләрнең осталары» фестивале үтте. Юмор кичәсенең төп максаты: церебраль паралич диагнозы куелган Илья Тажиев һәм Евгений Рожинга акчалата ярдәм җыю иде. Чыгыш ясаучылар икеләтә шат булуларын белдерде, чөнки бу көнне алар яраткан шөгыльләре белән балаларга ярдәм, файда китерделәр. Башка кунакларны да шул рәвешле мохтаҗларга ярдәм кулы сузарга өндәп, бәйрәмгә йомгак ясалды.

**Ахыры 2нче биттә.**



# Үсеш юлы

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

15 май көнне Казан федераль университетында яшь галимнәргә ОПТЭК компаниясе грантын тапшыру тантанасы узды. Чарада фәнни эшчәнлек буенча проректор Данис Нургалиев, компаниянең генераль директоры Максим Игельник катнашты.

Грантка 35 яшькә кадәр биология, медицина, химия, геология, физика, нанотехнологияләр кебек юнәлешләр буенча фәнни һәм укыту эшчәнлегендә катнашкан студент, аспирант һәм укытучылар дәгъва кыла. Программаның төп максаты – яшь галимнәргә акчалата ярдәм итү, яңа технология һәм методлар хисабына һөнәри үсешкә ирешүгә булышу, фәнни-тикшеренү эшләрен заманча җиһазландырылган лабораторияләрдә башкару мөмкинлеге тудыру.

Җиңүчеләрне сәламләп, Данис Нургалиев Казан университеты һәм ОПТЭК компаниясе арасында күп еллардан бирле дуслык җепләре булуын, якын киләчәктә микроскопия буенча уртак фәнни-тикшеренү үзәге ачылачагын әйтте.

Быел конкурска барлыгы 370 гариза кабул ителә һәм 268 е алдагы турга үтә. Эксперт советы 94 кешене җиңүче итеп билгеләде. Бу, 2010-2011 елгы конкурс белән чагыштырганда, 26 кешегә күбрәк дигән сүз. Казаннан быел 7 эш акчалата ярдәмгә ия булачак (15 лауреат), шуларның икесен КФУ ның яшь галимнәре тәкъдим иткән. Җиңүчеләргә, җыелган баллар күләменнән чыгып, акчалата грант биреләчәк.

Гомумән, Казанның яшь галимнәре югары күрсәткечләргә ия була. КФУдан Наталья Ланник һәм Валерия Федотова эшләре мөмкин булган 12 баллдан 11 балл җыя.

Акчалата ярдәмнән тыш, ОПТЭК лауреатларга кирәкле җиһазлардан файдалану, эш нәтиҗәләрен фәнни журналларда бастыру һәм халыкара конференция-форумнарда катнашу мөмкинлеге бирә.

«Быел конкурс дүртенче мәртәбә уздырыла. Аның географиясе артты, эшләрнең тематикасы да үзгәрде. Шулай ук конкурста югары уку йортлары гына түгел, академик институтлар да катнаша ала», – ди компания директоры Максим Игельник.

ОПТЭК фән, мәгариф, инновацион индустрия, сәнәгать һәм сәламәтлекне саклау өлкәсендә югары технологияле чишелешләр тәкъдим иткән эре компания булып тора. Ун елдан артык Россия һәм БДБ илләрен алдынгы дөньякүләм әйдәп баручы брендларның оптик һәм электрон-оптик җиһазлары белән тәэмин итә. Carl Zeiss компаниясенең эксклюзив вәкиле санала.

## • Халыкара бәйләнешләр

# Белем - милләтләр күпере

**Рамил ХАННАНОВ**

Үткән ике-өч көндә Татарстан Республикасында Төркмәнстан Республикасы делегациясе булды. 15-16 май көннәрендә Казан федераль университетында да төрле чаралар үтте.

15 май көнне Төркмәнстанның Министрлар кабинеты рәисе урынбасары Сапардурды Тойлыев, Төркмәнстан Мәҗлесенең Кеше хокукларын һәм ирекен яклау комитеты рәисе Пирназар Ходайназаров, Магтымгулы исемендәге Төркмән дәүләт университеты ректоры Гуртиниязь Ханморадов җитәкчелегендәге кунаклар Казанның төрле югары уку йортларында белем алучы Төркмәнстан студентлары белән очрашты.

**Ахыры 2нче биттә.**



Алия Галимуллина фотосы

## • Ике авыз сүз

**Башы 1нче биттә.**

15 май көнне КФУда I берләшкән профсоюз конференциясе узды. Көн тәртибендә өч сорау һәм төрлеләр каралды. Конференциядә 233 делегатның 181е катнашты. Профсоюз җитәкчесе В.Рубцов өч ел дәвамында башкарылган эшкә нәтиҗә ясады. Барлыгы 1 млн 509 600 сум күләмендә матди ярдәм күрсәтелгән. Зурлар өчен – 181, балалар өчен 160 юллама хакы түләнгән. Реорганизациядән соң профсоюзда барлыгы 3847 әгъза санала. Конференциядә катнашучылар яңа профсоюз эшчәнлеге белән генә танышып калмады, ә үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап та алды. Конференциядә катнашкан административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе А.Хашов делегатларны бердәм оешмага берләшүебез белән котлады һәм уку йорты турында тагын да тулырак мәгълүмат җиткерде.

• • • •

16 май көнне Казан федераль университеты ТР ның Министрлар Кабинеты каршындагы Төп архив идарәсе белән берлектә Казанның Көнчыгышны өйрәнү тарихы буенча фәнни-агарту укулары уздырды. Укуда катнашучылар үз чыгышларында Казан университетында хезмәт куйган Көнчыгышны өйрәнүче галимнәр эшчәнлеге, ориенталистика фәне үсешенә керткән өлешләре, Казанда Көнчыгышны өйрәнү тарихы һәм үзенчәлекләре кебек темаларны яктырттылар.

• • • •

Бүген Филология һәм сәнгать институтының Актлар залында «Казан утлары» журналының чыга башлавына 90 ел тулуга багышланган «Казан утлары» журналы һәм милли мәдәният» дип аталган төбәкара фәнни-гамәли конференция уза. Чарада танылган язучы-шагыйрьләребез, галимнәр катнаша. Бу турыда тулырак киләсе санда укый алассыз.

• • • •

18 май көнне – Халыкара музейлар көнендә 13 сәгать 30 минутта КФУ тарихы музеенда 2012 елда бүләк ителгән экспонатларны халыкка тәкъдим итү чарасы уза. Биредә галимнәрнең шәхси әйберләре (Казан университеты студенты, академик Камил Вәлиев коллекциясе), уникаль экспонатлар булачак.

• • • •

22-24 май көннәрендә Төбәкара клиник-диагностик үзәкнең (МКДЦ) конференцияләр залында медицина-биологик проблемалар, фундаменталь һәм трансляцион медицина буенча дисциплинара семинар узачак. «Гемостаз системасы патологиясен тикшерү» темасына лекция һәм гамәли семинар үтәчәк. «Тромбоимеджер 2» җиһазын өйрәнү һәм анда эшләп карау мөмкинлеге булачак.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

## • Халыкара бәйләнешләр

# Белем - милләтләр күпере

**Башы 1нче биттә.**

Чараны алып барган КФУ президенты Мәкъзүм Сәлахов кунакларны һәм барлык студентларны сәламләде. «Белем – ул дөнья халыклары илчесе, төрле милләтләр арасында күпер салучы. Бүген КФУда җиде дистәдән артык Төркмәнстан студенты белем ала. 2008 елда Төркмәнстан Республикасы президенты булып китүчә, багланышларыбыз тагын да көчәйде», – дип белдерде ул. Кунаклар белән очрашуда КФУ ның тышкы элемтәләр буенча проректоры Линар Латыйпов һәм Тышкы элемтәләр департаменты директоры Андрей Крылов та бар иде.

Тарихтан хәтерләсәк, заманында Казанның Император университеты Шәрык илләре һәм Россия дәүләте арасында дуслык җепләрен ныгыту, фән һәм мәгариф өлкәсендә багланышлар булдыру максатыннан ачыла. Ул беренче көннәреннән үк төрки дөньяда алдынгы югары уку йорты булып эшләп китә. Әлеге үзенчәлек бүген дә үз көчен югалтмый – университетның абруе арткаынан-арта бара.

Моның шулай булуын Сапардурды Тойлыев та искәртте һәм студентларга: «Безнең республика җитез хәрәкәтләр белән алга бара. Укып бетергәч, һичшиксез, сезне үзебездә көтәбез. Эш урыннары әзер, торак белән тәэмин итәчәкбез», – диде, Ватан, милләт өчен тырышуларын үтенде.

Студентлар да сораулар әзерләп килгән иде. Аларны КФУ дипломының Төркмәнстанда әһәмияте булубулмау, бездә бакалавр булып чыккан яшь белгечнең Төркмәнстанда (бу республикада икебаскычлы белем бирү системасы кертелмәгән) эш табу, туган якларыннан Казанга, Мәскәү аша түгел, турыдан-туры килә алу мәсьәләләре борчый иде. Сапардурды Тойлыев һәр сорауның уңай хәл ителәчәгенә вәгъдә бирде.

Кичә исә университетта, визит кысаларында, төркмән әдәбияты классигы Мәхтүмкули Фрагиның туган көне һәм Төркмәнстанда Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәренә (май башында узды) багышланган «Татарстан-Төркмәнстан: кайбер нәтиҗәләр, хезмәттәшлек тарихы һәм перспективалары» дип аталган фәнни конференция узды. Биредә татар-төркмән, россия-төркмән хезмәттәшлеге тарихы һәм перспективалары; мәдәният, фән һәм мәгариф өлкәсендә Төркмәнстан һәм Татарстан багланышлары; Урта Азия һәм Урта Көнчыгыш илләрендә сәяси, социаль-икътисади, мәдәни мәсьәләләрне чишүдә Россия һәм аның төбәкләренең роле; Россия уку йортларында, фәнни үзәкләрендә Урта Азия халыкларының мәдәнияят тарихын һәм телләрен өйрәнү һәм укыту; Урта Азия һәм Идел-Урал дәүләтләре, халыклары арасындагы багланышлар үсешендә галим һәм сәяхәтчеләрнең роле кебек сораулар каралды.

## • Бәйге

# Бердәмлектә - көч!

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

**15 май көнне КФУда «Иң яхшы академик төркем» бәйгесе булып үтте. Әлеге чарада университетыбызның барлык институт-факультетларыннан да «иң-иң» дип табылган төркемнәр көч сынашты.**








«Иң яхшы төркем» конкурсы университет кысаларында инде җиденче тапкыр үткәрелә. Башка еллардан аермалы буларак, быел анда «Иң яхшы куратор» номинациясе дә кертелгән. Мондый төрдәге чаралар, әлбәттә, төркем эчендә бердәмлекне, бергәлекне һәм активлыкны арттыруга юнәлтелгән.

Исегезгә төшерәбез: бәйге сентябрь аенда ук старт алган иде инде. Катнашырга теләүче төркемнәр I турда деканатларга кирәкле документларны җыеп тапшырды. Институтлар үзләреннән иң яхшы дип табылганнарын тәкъдим иткәннән соң, жюри һәр номинациядә бишәр төркемне сайлап алды. Һәм инде 15 май көнне, сайлап алынган бөтен төркемнәр дә очрашып, III турда үзара ярыштылар. Тагын шунысын искәртеп узасым килә: жюри әгъзалары конкурска сайлап алган вакытта, барлык төркемнәрнең дә уку елы дәвамында нинчек укуларын, ягъни өлгереш балларын исәпләп чыгарганнар. Шул ук мәдәниятсәнгать, спорт өлкәсендә төркемнәрнең ни дәрәҗәдә актив эшләгәнлекләре дә исәпкә алынды. Тагын бер мәҗбүри шарт университет газеталарында группа турында мәкалә бастыру иде.

«Иң яхшы куратор» исеменә лаек булырдай остазлар үзләренең 5 минутлык чыгышларында бөтен эшчәнлекләрен яктыртырга тиеш иде. Рус әдәбияты кафедрасы доценты Татьяна Карпеева, гомуми һәм махсус психология кафедрасы доценты Наталья Калацкая, юридик факультет доценты Римма Әмирова, экология һәм география институты ассистенты Марина Исаева, Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институтыннан Людмила Князева эчтәлекле презентацияләр һәм, әлбәттә, үзләренең студентлары ярдәмендә иң алдынгы кураторларның нинди сыйфатларга ия булырга тиешлеген күрсәтте.

«Иң яхшы төркем» бәйгесендә III турның шарты жюри алдында иҗади формада чыгыш ясау иде. Моннан тыш, кумәклек, оригинальлек, үз белгечлекләренә басым ясау, группаның традицияләрен һ.б. үзенчәлекләрен чагылдыру кебек нюанслар да истә тотылырга тиеш. Әйтергә кирәк, төркемнәрнең бәйгегә карашлары төрле булганлыгы залдан карап утыргандачык күренде. Кайберләренең чыгышлары шактый сүлпән, ә икенчеләрнең, чын мәгънәсендә, җиңәргә дип килгәнлеге сизелеп торды. 5 минут дәвамында төркемне бөтен яклап белеп бетереп булмаса да, күмәк эшләү рәвешен күрсәтергә мөмкин иде. Бу яктан конфликтология, механика һәм математика, татар филологиясе, журналистика бүлекләрендә укучы һәм КФУ ның Яшел үзән филиалы студентлары үзләренең төркемнәре чын-чынлап бердәм икәнлеген күрсәтте. Бәйгенең исеме үк «Иң яхшы төркем» дип аталгач, чыгышлар да күмәк, барлык студентлар катнашында булырга тиештер кебек. Шуңа карамастан, кайбер төркемнәрдә бу шарт бик үк исәпкә алынып бетмәгән иде. «Фәкыйрьлек» хәтта 6-7 студенттан гына торган төркемнәрнең күмәк җырлауларында да сизелде. Ә сәхнәдә тулы составта бердәм булган төркемнәргә сокланмыйча мөмкин түгел. Егетләрдән генә торган Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты төркеменең чыгышы аеруча үзенчәлекле булды: алар биремне оператив һәм оешкан төстә башкарып чыкты. Икътисад һәм финанс институты студентлары үз стильләрендә: бик тә җитди һәм төгәл саннар белән төркемнәренә характеристика бирделәр. Тарихчылар, химиклар, психологлар, биологлар, мәгълүмати технологияләр бүлегеннән чыгыш ясаучылар – һәммәсе дә үзләренең төркемнәрен бары тик уңай яктан гына күрсәтергә тырышты...

Ахырдан һәр төркем интеллектуаль яктан оешкан булуын, фикерләү осталыкларын күрсәтү максатыннан, «Сюрприз» дип аталган биремдә көч сынашты.

Нәтиҗәләре киләсе атнада гына билгеле булуга карамастан, бәйге азагында конкурсантларның йөзләрендә елмаю, төркемнәре өчен горурлык хисләре сизелеп тора иде. Җиңүче төркемнәргә Россия шәһәрләренә экскурсиягә юллама биреләчәк: I курс студентларына – якын-тирә шәһәрләргә, ә югары курсларга Санкт-Петербург шәһәрендә ял итеп кайту мөмкинлеге булыр дип көтелә. Барлык этапларны да яхшылап исәпләп чыгарганнан соң, бүләккә кайсы төркемнең лаек булуын жюри рәисе икенче атнага игълан итәчәк. Сезне җиңүчеләр белән алдагы санда таныштырырбыз.

*Диана Поварова фотолары*

## • Табигать сагында

# Үсентеләр тормыш башлый

**Рөстәм ФӘРХУЛЛИН,**
Экология һәм география институты ассистенты

**Шушы көннәрдә Халыкара инвалидларның хокукларын яклау көне кысаларында «Казан – 2013» Башкарма дирекциясе «Ковчег» инвалидлар җәмгыяте белән берлектә агачлар утырту акциясе уздырды.**

Чарада мәктәп һәм интернатларда тәрбияләнүче сәламәтлекләрендә тайпылышлары булган 220 укучы, шулай ук университетыбызның географик һәм экологик белем бирү бүлеге волонтёрлары, башка вузлардан волонтёр-студентлар катнашты. Агач утырту кебек изге эшкә ТР Премьер-министры Илдар Халиков та кушылды.



М.Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркында волонтёрлар укучылар өчен төрле күңел ачу һәм интеллектуаль уеннар да уздырды, концерт оештырылды.

2013 елда узачак Универсиаданың төп объектларының берсе булган Волейбол үзәгендә һәм М.Горький исемендәге паркта шул көнне утыртылган нәни агаччыкларның шаулап үсеп китүендә шик юк.

• Жиңүнең 67 еллыгына

# Дәһшәтле еллар кайтавазы

**Роза ХӘМИТОВА**

Заманында безнең университетта белем алган Роза Хәмитова – сугыш елы баласы. Аның хатирәләрендә дәһшәтле сугыш нинди эз калдырган?! Юк, аның гына түгел, ә бөтен сугыш чоры балаларында... Көндәлек битләрендә – ачы хакыйкать.

***(Дәвамы. Башы алдагы саннарда).***

***

Гөлҗиһан апа ярдәмендә «Әлифба»ны да үзләштереп бетердем. «Әлифба»дан соң «Букварь», «Туган тел» – берсе дә калмады... Шуннан соң ул мине Таифә тәтәйләргә алып китте. Ә алар өстәл янында кичке ашка җыелышканнар... Кичке ашка нәрсә соң? Бөтенесендә дә кычыткан шулпасы, әз-мәз генә алабута көлчәсе. Алар безгә: «Түрдән узыгыз, әйдәгез, бергәләп сыйланыйк», – диләр. Тәкъдимне кабул итәргә ярамый. Без, уңайсызланып кына: «Юк, рәхмәт, без тук», – дип алдарга мәҗбүр. Шуннан соң Гөлҗиһан апа мине стенага таба борып бастыра да барлык сөйләшүләрне үзе башкара. Башка иптәш кызларым – Нюра, Лиза, Мәрхәбә дә нәкъ шулай эшлиләр...

*1944 ел*

Башка җирләргә эш буенча йөргәндә, әни мине һәрчак үзе белән алды. Хәдичә апаның өендә 3-4 бала була иде. Балаларның өсләрендә киемнәре юк диярлек, ялангачлар. Йөзләре, башлары әллә нинди саргылт, кызгылт кан таплары белән тулган.

– Нәрсә булган аларга? – дип сорыйм әниемнән.

– Төче авыруы... Ачлыктан. Ашарга черек бәрәңгедән башка бернәрсә дә юк. Шуңа балалар авырый да, – дип, әнием сабыр гына аңлата.

Урамда бер алачык бар. Ул агачтан та, кирпечтән дә түгел, ә тирес белән кызыл балчык кушып ясалган. Монда ятим Бубновлар: ике малай һәм бер кыз яши. Эчтә кысан, караңгы, кечкенә тәрәзәдән яктылык көчкә төшеп тора. Мич ятагында – искемоскы, чүпрәк-чапрак. Бу бичара балакайлар ничектер яши бирәләр, кайсыдыр яклап колхоз ярдәм итә, ниндидер пособиеләр дә алдылар шикелле. Олы апалары еракта яши. Кайвакыт ул да посылкаише әйберләр җибәреп тора.





Бервакыт, малайларның Гена исемлесе ак чалбар киеп чыккан, купшыланып, бер тузан төшсә дә, чалбарын каккан булып йөри. Ә мин бу чалбарның ирләрнеке икәнен дә, аңа шактый гына зур, уңайсыз булуын да күреп торам. Шулай да шатлыгын бозасым килми: йөзендә елмаю күрү миндә ниндидер рәхәт тойгылар уята. Озак тормастан, ул балаларны апалары үз янына алып китте. Без аларны бүтән күрмәдек.

Бу вакытларда мин мәктәпкә бик еш йөри башладым. Бер салкынчарак кына бүлмәдә әнием дәресләр бирә, ә икенче бүлмәдә рус балалары укый. Барлыгы 4 класс. Мин парта араларында йөрим яки үземнән зуррак берәр укучының дәреслекләрен, китапчыкларын, глобусларын караштыргалыйм. Шундый түгәрәк җир шарыннан ничек итеп кешеләр егылып төшми икән?! Гаҗәп... Әмма әнием миңа барысын да җайлап кына аңлата: «Безнең Җиребез шулкадәр зур ки, хәтта без аның шар формасында булуын сизмибез дә».

Мәктәптә еш кына балаларның борыннарыннан кан китә. Ә минекеннән – юк. Ни өчен? Сәбәбен әниемнән сорыйм. «Балалар ач, ашарга булмаудан газапланалар, шуңа күрә борыннарыннан кан китә».

Тагын бер бәла бар мәктәптә: кызлар яулыкларын салмыйлар. Чәч белән яулык бер-берсенә ябышып киезләнеп ката, яулыкны салдыру өчен, чәчләрен кисәләр.

Мәктәптә фронт өчен посылкалар җыялар. Мин дә тәмәке янчыгы тектем, янчыкка әнием азрак тәмәке дә салды. Зуррак апалар оекбашлар, бияләйләр, җылы киемнәр әзерләделәр. Бияләйләр арасында үзенчәлеклерәкләре дә була иде: алар ике бармак чалы итеп тегелгән. Әнием әйтә: «Алар снайперлар өчен махсус шулай эшләнә», – ди.

Колхоз рәисе Газиз абый кырыс һәм әһәмиятле кеше. Үзе Герой исемле ак айгырга атланып йөри. Кайвакыт Герой әнием белән мине дә чанада Кама Тамагына алып китә. Колхозның бөтен атлары ябык, мескен хәлдә, ә Герой – герой инде, нәрсә әйтәсең!

Рәисне еш кына хатын-кызлар сүгә. Җәй көне ул эшчеләрне каршы ала, озатып кала, соңга калучыларны «эләктерә». Шулай да безнең Фрунзе исемендәге колхоз артта калганнардан түгел, урланган бер бөртек өчен төрмәгә җибәргәннәре булмады. Беренче уңышны рәис дәүләткә түгел, ә ач колхозчыларга тарата.

Шуның өчен аны Кама Тамагына бюрога чакырттылар, ләкин ул үзе бармады, әниемне җибәрде. Ә минем әнием – парторг – шулай ук кырыс, үзе һәм башкалар өчен җавап бирә торган кеше. Ул бу юлы да мәсьәләне тавышсыз гына үткәреп җибәрде.

Бикәй авылында өйләрнең тәрәзәләре җылылык саклый торган итеп эшләнгән: яртылаш кадакланган, пыяла рамның өске өлешенә генә куелган. Рамнан кышын җил өреп тора. Киемнәр өчен материал да юк. Сугышка кадәрге пәрдәләр чоланны өй белән бүлеп тора. Уйлап йөрим: материалы миңа кофтага ярар иде...

Тәрәзәләр төнгә нәрсә туры килә, шуның белән каплана. Яктылык күренмәсен өчен ул. Чөнки фашистлар теләсә кайсы авылны утка тотарга мөмкин. Ә немецлардан мин куркам. «Таня», «Наука ненависти» исемле газеталарда аларны ямьсез итеп сурәтлиләр... Мин хәтта ул газета, журнал битләрен ачып карарга да куркам.

...Төрле фронтлардан яраланган солдатлар кайта башлады: Кәшшаф абый, Кәримулла абый...

*1944 ел*

***(Ахыры киләсе санда).***

• Сәнгать

# Шәхес көче - күңел канатларында

**Флорида ФОМИНА,**
Татар халык хоры солисты,
КДУ ның 1974 елгы чыгарылыш студенты

Мәшһүр университетның Актлар залы тәрәзәләреннән күңелне изрәтеп татар җыры, татар моңы агыла. Сәхнәдә шушы университетның яңа буын шәкертләре, аспирантлары хорның җитәкчесе Ирнис Рәхимуллинның һәр хәрәкәтенә буйсынып, илһамланып, залдагы тыңлаучыларны сихри җыр дөньясында йөздерәләр.

Мин 28 ел элек шушы хорчылар арасында җырладым. Моңа кадәр әле аны читтән бер мәртәбә дә тыңлаганым юк иде. Менә, ниһаять, бу бәхет насыйп булды. Шушы авазларга чумып, күмелеп, иләсләнеп тыңлап, үземнең беренче тапкыр хор репетициясенә килгәнемне, беренче чыгышларны, беренче уңышларны, беренче тапкыр Ирнис абыйның мактау сүзләрен искә төшерәм, яшьлегемә, студент елларыма кире кайтам.

Без, хорчылар, күбебез авыл балалары, дүрт тавышка җырлауның нәрсә икәнен белмәүчеләр (ә распевка, нота дигән сүзләр безнең күбебез өчен таныш булмаган төшенчәләр иде), I курста Ирнис абыйның тылсымлы кулларына эләгеп, күп тавышка җырлауның нечкәлекләренә өйрәнә башладык, үзебез өчен күп ачышлар ясадык. Хор белән без кайларда гына булмадык: Татарстанның шәһәр һәм авылларында, Мәскәү, Санкт-Петербург, Рига, Вильнюс, Уфа, Әстерхан, Волгоград шәһәрләрендә. Кая гына барсак та, безне җылы каршы алдылар, яратып тыңладылар, күңелләрне сөендереп алкышладылар.



Диана Поварова фотосы

Ирнис абый безне хорда җырларга өйрәтү белән генә канәгатьләнми, зур күләмле симфоник әсәрләр белән дә таныштырырга тырыша, Опера һәм балет театрында, Консерваториядә уза торган концертларга чакыра иде. Шулай ул бездә музыкаль зәвык тәрбияләде, җитди музыканы яратырга, аңларга булышты. Биш курс буена бу шәхестән алган аң-белем, илһам сәнгатьне сөюгә һәм аңа күңелнең даими мохтаҗ булуына әйләнү безгә һөнәри тормыш юлын башлаганда зур ярдәм итте. Моның өчен Ирнис абыйга гомер буе рәхмәт укыйм.

45 ел шушы университетка, аның татар халык хорына (халык хоры дәрәҗәсенә житү – шулай ук Ирнис абыйның фидакарьлеге, тырышлыгы нәтиҗәсе) тугры яшәү өчен, олы йөрәкле кеше булырга кирәк. 45 ел эчендә күпме шәкертнең иң нечкә күңел кылларын чирткән, зур сәнгать дөньясына аяк бастырган Ирнис абый – бүген дә искиткеч энергияле, җаны-тәне белән шушы коллективны зур җиңүләргә әйдәүче илһам иясе. Юбилей концерты коллективның профессиональ яктан нык үскәнен күрсәтте. Бу мине бик шатландырды. Һәр авазның, һәр нотаның яңгырашына игътибарлы Ирнис абый. Ноталарның төгәл яңгыравына татар моңы, күңел җылылыгы, хис байлыгы өстәлү хорны тыңлап туя алмаслык итә.

Бүген хор, күңелләрне илһамландырып, тагын да чистарак, тагын да көчлерәк яңгырый. Хордан үсеп чыккан ике ансамбль («Былбыл», «Хәят») дә минем өчен яңалык булды. Нәфис, җылы, дәртләндергеч репертуарлары күңелләргә илһам өсти.

Шушындый җәүһәр коллективка матди яктан да, башка яктан да ярдәм итеп, профессиональ яктан зур уңышларга ирешүне тәэмин итеп, аны саклап калсын иде университетыбыз. Киләчәк буын студентларын тәрбияләүдә (ә бүгенге көндә бу вазифадан беркем дә азат түгел) бу эш иң изге бурычларның берсе. Моннан соңгы елларда хорда җырлаган күп буын шәкертләр дә үзләренең туган университетына хор өчен зур рәхмәтләрен белдереп баш иярләр.

*Уфа шәһәре.*

***Редакциядән:*** *концерт алдыннан Татарстан китап нәшриятында хор репертуарына кергән әсәрләрнең ноталар җыентыгы басылып чыкты.*

**РАБОТА СТУДЕНТАМ и ДИПЛОМНИКАМ**

НПФ БЛАГОСОСТОЯНИЕ

В один из крупнейших Российских негосударственных пенсионных фондов НПФ «БЛАГОСОСТОЯНИЕ» (российские железные дороги) требуются сотрудники на должности финансового консультанта и руководителя группы.

• оформление по договору,
• гибкий график работы, возможность совмещения,
• оплата своевременная, обучение за счет компании,
• **оклад до 20 000** +премии(оклад по результатам собеседования),

Требования: аккуратность, активность, коммуникабельность, желание зарабатывать.
**Опыт работы не обязателен !!!**

**СТУДЕНТ - НЕ УПУСКАЙ ВОЗМОЖНОСТЬ - ЗАРАБОТАТЬ И ПОЛУЧИТЬ ПЕРВОНАЧАЛЬНЫЙ ОПЫТ РАБОТЫ В СВОБОДНОЕ ОТ УЧЕБЫ ВРЕМЯ!!!**

**Все подробности:**
**г.Казань, ул Московская, 31/6, офис 203**
**или по телефонам:**
**(843) 240-18-14, 259-18-89**
**http://www.vasheblagosostoyanie.ru/**

реклама

Илһам канатында

# Әдәбиятның киләчәге сагында

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

Габдулла Тукаебызның: «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул», – дигән сүзләре, чын мәгънәсендә, IV Бөтенроссия «Илһамлы каләм – 2012» әдәби әсәрләр конкурсының шигаре булырлык иде. Татар милләте юкка чыга бара, әдәбият-сәнгать белән кызыксынмыйлар, дигән заманда КФУ ның татар филологиясе бүлеге оештырган әлеге конкурс үзенә Россиянең төрле төбәкләреннән 332 укучыны җәлеп итте.



■ Гөлүсә Фәизова, Апас районы Акхуҗа мәктәбе укучысы



■ Таһир Исмәгыйлев, Арча шәһәре укучысы



■ Алсу Вахитова, БРның Бишбүләк районы укучысы

Ильяс Гыйләҗетдинов фотолары

«Илһамлы каләм» республикабызда гына түгел, чит төбәкләрдә сибелеп яшәүче милләттәшләребезне дә мәркәзебезгә җыеп кына калмый, ә татар әдәбияты тарихын, бүгенгесен, киләчәген язачак яшь иҗатчыларны да барлый.

Илһам канатлы, хыялга бай, яңа сүз әйтергә омтылган кешеләрдә генә була, диләр. «Илһамлы каләм – 2012» конкурсында катнашучылар нәкъ менә шундыйлар иде, дип белдерә жюри әгъзалары. Бүлекнең галим-галимәләре, танылган язучы-шагыйрьләребез Ренат Харис, Мәдинә Маликова, Рифә Рахман, Халисә Ширмән кебек абруйлы шәхесләрдән торган жюри вәкилләре, Язучылар берлегеннән котларга килгән шагыйрь Ркаил Зәйдулла, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының матбугат хезмәте җитәкчесе Гөлназ Шәйхи дә үз чыгышларында моны исбатлады.

Әүвәл, инде традицион рәвештә кабул ителгәнчә, яшь иҗатчылар һәм аларны бәйгегә әзерләүче мөгаллимнәр белән жюриның эшче төркеме «түгәрәк өстәл»дә фикер алышты, киңәш-тәкъдимнәр әйтелде, Казан федераль университеты, аеруча да татар филологиясе бүлеге турында мәгълүмат җиткерелде. Шуннан соң барча халык Актлар залына агылды. Биредә тантаналы бүләкләү кичәсе көтә иде.

«Илһамлы каләм» бәйгесенең беренче турына 332 укучыдан эшләр кабул ителгән булса, бәйгенең икенче турына аның 89 ы гына үткәрелгән. Шул меңәрләгән иҗади эшләр арасыннан җиңүчеләр кичәдә «сюжет һәм хикәяләү үзенчәлекләре», «композицион осталык», «авторның үз стилен чагылдырган әсәр», «иҗади зәвык һәм сәнгатьлелек», проза жанрлары арасында иң яхшы әсәр, поэзия төрендә иң уңышлы әсәр, публицистика һәм драматургия юнәлешендә иң шәп әсәр номинацияләрендә бүләкләнделәр. Әлеге укучыларга җиңү яулашкан укытучылар, сәхнәгә чакырылып, аларга шулай ук оештыручыларның рәхмәт хатлары тапшырылды. Иң соңыннан Гран-прига ия конкурсант билгеләнде. Төп җиңүче исеменә инде дүрт ел дәвамында конкурста катнашып килгән, узган ел да проза төрендә I урын яулаган Актанышның 1 нче мәктәбеннән 11 сыйныф укучысы Гүзәл Фарсыева лаек булды.

Конкурсны оештыручылар – КФУ ның Филология һәм сәнгать институты, Татарстан Республикасының Язучылар берлеге һәм Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты татар укучылары арасында сәләтлеләрне барлау, тәрбияләү һәм үстерү, шулай ук укучыларда иҗади һөнәрләргә карата кызыксыну уяту, татар халкының телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен саклау һәм үстерүне максат итеп куя. Миңа калса, әлеге максатлар елдан-ел тулысы белән тормышка ашырыла. Узган өч ел эчендә «Илһамлы каләм»дә катнашкан дистәләгән укучы инде бүген безнең Казан университетының төрле институт-факультетларында, аеруча да татар филологиясе бүлегендә белем ала, илһамланып яшәүләрен дәвам итә. Быелгы конкурсантлар арасында да нәкъ менә сезгә укырга киләчәкбез, дип канатланып кайтып китүчеләр шактый иде. Конкурсның электрон почтасы оештыручыларга, мөхтәрәм жюри әгъзаларына рәхмәт сүзләре тулы хатларны инде менә ничәнче көн кабул итә. «Илһамлы каләм»нең бигрәк тә ел саен катнашып килгән Оренбург, Самара, Саратов, Башкортстан, Пенза, Пермь, Ульян, Киров, Мари-эл, Чувашия төбәкләрендә яшәүче татар укучыларына канат куюы күңелне сөендерә. Заманында бит Татарстаннан читтә урнашкан әлеге яклар әдәбиятның классиклары булган күпме әдип биргән.



■ Җиңүчеләрне Халык шагыйре Ренат Харис котлый

Руслан Гыйниятов фотосы

Төркем-төркем укучылар, укытучылар, әти-әниләр быел да, бер-берләре белән дуслашып, илһамланып, университетыбыз турында бай мәгълүмат туплап, өйләренә таралышты. «Илһамлы каләм – 2013»тә очрашканга кадәр!

• 19 май – пионерлар көне

# Ленин бабайның шат оныклары

**Нәзирә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА,**
Филология һәм сәнгать институтының
белем бирү бүлеге җитәкчесе

Мин нигәдер бик еш йолдызчык таккан елтыр күзле малай-кызларны, бер йодрыкка бәйләгән, бер теләк, бер уй белән яшәткән пионер оешмасын, укучыларның чын дусты булган вожатыйларны, кызыл галстук бәйләгән пионерларны, дөрләп янган учакларны сагынып искә алам...

***(Ахыры. Башы алдагы санда).***

...Шул көннән башлап безнең командирыбыз, гөлләр үстерүчебез, санитарыбыз, китапханәчебез һәм спорт өчен җаваплы кешебез барлыкка килде. Аларның һәркайсы, йөзенә җитди кыяфәт чыгарып, үз вазифасын үтәргә кереште. Кемдер атна саен колаклар, тырнаклар тикшерде, кемдер дәреслекләрнең, дәфтәрләрнең торышын билгеләп йөрде, кемдер уку тизлеген бәяләде. Һәркем, хәленнән килгәнчә, чын октябрят икәнлеген исбатларга тырышты, пионер булырга әзерләнде.

Пионер буласы бик килә шул... Әнә аларның кызыл төстәге галстуклары әллә кайдан безне кызыктырып җилферди, шундый ук кызыл төстәге пилоткалары да солдатларныкы кеби кукраеп утыра. Әле җитмәсә, Пионер туган көн дип, 19 май көнне урманга да меңәләр. И-и-и, аларның барабан кагып, быргы кычкыртып, ал байраклар тотып урам буйлап барулары... Этләр хау-хаулап өрә, әбиләр ләхәүләләрен укый, әти-әниләр сокләна, ә без, билгеле, кызыгабыз. Бу алда санап киткән кешеләр барысы да капка төбендә басып калалар, ә пионерлар дөнья шаулатып урманга таба юл тота. Урманда, һәрвакыттагыча, отряд советы җитәкчеләре дружина советы җитәкчесенә рапорт бирә. Урман эчендә озак вакыт: «Отряд, равняйсь! ...смирно! ...за-пе-вай!» - сүзләре яңгырап тора.

*«Без – ленинчылар, без – пионерлар.*
*Безнең сафларда яңгырый җырлар.*
*Быргылар уйный, барабан кага,*
*Барабыз алга, барабыз алга!»* – дигән дәртле җырлар җырлыйлар, «Без һәрвакыт әзер!» кебек ялкынлы сүзләр кычкыралар. Иң кызыгы – йолдыз формасындагы учак янганны күзәтәләр. Учак яктысында:

*«Взвейтесь кострами, синие ночи!*
*Мы, пионеры, дети рабочих.*
*Близится эра*
*Светлых годов,*
*Клич пионера –*
*«Всегда будь готов!»* – дигән бик матур бер русча җыр да башкаралар.



И-и, без кайчан шулай, кулны күтәреп: «Без һәрвакыт әзер!» – дип, быргы кычкыртып, барабан кагып, урам буйлап йөрербез икән?! Билгеле, пионер булу кызык кына түгел, җаваплы да. Монда яхшы укучы булу өстенә, һәр яктан актив булу да кирәк. Әнә безнең күрше абый-апалар Сабира әбинең өен җыештыралар, утынын ярып өяләр, карын көриләр. Алар бу эшләрне шулкадәр рәхәтләнеп башкаралар, түзмичә, без дә аларга кушылып эшли башлыйбыз. Әле отрядлар арасында бертуктаусыз төрле ярышлар оештыралар. Кем күбрәк көл җыя, кем күбрәк тимер таба, кәгазь тапшыра. Линейкада: «Юрий Гагарин исемендәге отряд пионерлары, иң күп кәгазь җыеп тапшырып, беренче урынны алдылар!» – дигән сүздән соң аларның шатлануларын күрсәң! Пилоткалар һавага оча, «Ур-ра» кычкыралар – галәмәт инде менә. Иң алдынгыларны пионер лагерьларына юлламалар белән дә бүләклиләр әле.

Пионерларны әле комсомолга кабул итәләр икән! Алары турында берни белмим. Түшләренә алар «ВЛКСМ» дип язылган значок тагып йөриләр. Ул «ВЛКСМ»ни аңлатадыр – дусларым арасында да белүчеләр юк. Зурраклардан кемдер: «Вәли лапаста кәҗә савып маташа», – ди. Нинди Вәли? Нинди кәҗә? Һич башыма сыймый. Шаяралар бугай. Әле кайберләре: «Возьми лопату – копай себе могилу», дип тә җиффәрәләр. Кыяфәтләренә карасаң, бер дә шаяралар димәссең. Комсомолга керү өчен, Устав дигән нәрсә өйрәнергә кирәк икән! Өйрәнү генә түгел, шул Уставта язылганча гына яшәргә, ди... И-и, пионер булу шәбрәк ахрысы, комсомол артык катлаулы күренә. Эх, менә пионер булсаң иде!...

Менә шундый матур уйлар иде безнең башта...

Хәзерге мәктәп балаларының уйлары ямьсез, кызыксынулары тар димим мин. Бүгенге көндә Татарстан варислары берлеге уңышлы эшләп килә. Төрле хәрәкәтләр, юнәлешләр, балаларның сәламәтлеген ныгыту, сәләтен үстерүне максат итеп куйган лагерьлар бар. Әле, җитмәсә, «Бердәм Россия» партиясенең кайбер вәкилләре элекке пионерлар рәвешендә гомумроссия балалар оешмасын булдырмакчы. Афәрин! Уңышлар... Балаларны, яшүсмерләрне урамнан саклап калуның төрле юлларын эзләргә күптән вакыт инде. Нинди генә оешма, хәрәкәт булса да, алар яшь буынга Ватаныбызның лаеклы кешеләре булып үсәргә ярдәм итсен иде.

Ә мин барыбер дөрләп янган учакларны сагынам...

СМОТРИ
UNIVERSMOTRI.RU

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.